Совет Старочукалинского
сельского поселения Дрож-
жановского муниципального
района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1061672003876 ИНН 1617003290
==========================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы

27сентябрь 2022 года № 19/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында

“Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында” гы 9 февраль 2009 ел № 8-ФЗ Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставының 32 матдәсенә таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә урнаштыру вакыты периодлылыгын билгеләргә – айга 2 тапкырдан азрак түгел.
3. Интернет челтәрендә урнаштырылган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүматның яңартылу срокларын билгеләргә – ихтыяҗ туганда.
4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә урнаштыру һәм яңартып тору өчен җаваплы зат итеп Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы башкарма комитеты ссәркәтибе Якупова Илсөяр Фиалит кызын билгеләргә.
5. Әлеге Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карар кул куелган моменттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чокалы авыл
җирлеге Советының
09.2022 ел № 19/1
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турындагы
Н И Г Е З Л Ә М Ә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында” гы 9 февраль 2009 ел № 8-ФЗ Федераль законга туры китереп, мәгълүматтан файдаланучыларга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары (алга таба - ҖҮО) эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- *сорау* - мәгълүматтан файдаланучының телдән яки язмача, шул исәптән электрон документ формасында, җирле үзидарә органына яки аның вазифаи затына әлеге орган эшчәнлеге хакында мәгълүмат бирү турындагы мөрәҗәгате;

- *җирле үзидарә органының рәсми сайты* – электрон адресы үз эченә җирле үзидарә органы хокукында булган доменлы исемне алган, ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат урнаштырылган Интернет челтәрендәге сайт.

- *ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат* – ҖҮО тарафыннан яки җирле үзидарә органына буйсынган оешмалар (алга таба – буйсынган оешмалар) тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә булдырылган, яки күрсәтелгән органнарга һәм оешмаларга кергән мәгълүмат (шул исәптән документлаштырылган);

ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат исәбенә шулай ук күрсәтелгән органнар һәм оешмаларның структурасын, вәкаләтләрен, оештырылу һәм эшчәнлеге тәртибен билгеләгән муниципаль хокукый актлар, алар эшчәнлегенә кагылган башка төр мәгълүмат керә;

- *Мәгълүматтан файдаланучы* – ҖҮО эшчәнлеге хакында мәгълүмат эзләүче граждан (физик зат), оешма (юридик зат), иҗтимагый берләшмә. Мәгълүматтан файдаланучылар булып шулай ук, 9 февраль 2009 ел № 8-ФЗ Федераль законга туры китереп, күрсәтелгән мәгълүматны эзләүче дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тора.

3. Әлеге Нигезләмәнең гамәли тәэсире ҖҮО ның үз эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре сораувы буенча

Россия Федерациясендә массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законнарда көйләнмәгән өлештә бирүе белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла.

4. Әлеге Нигезләмәнең гамәли тәэсире кагылмый:

җирле үзидарә органнары тарафыннан эшкәртелүче шәхси мәгълүмат белән файдалануга бәйле мөнәсәбәтләргә;

2) җирле үзидарә органнарының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә;

3) җирле үзидарә органнары тарафыннан үз эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә дәүләтнең башка органнарына, башка җирле үзидарә органнарына бирү тәртибенә.

5. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүнең төп принциплары булып:

1) ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматның, Федераль законнарда каралган очраклардан башка, ачык һәм файдаланырлык булуы;

2) ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматның дөрес һәм үз вакытында бирелгән булуы;

3) ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны теләсә нинди законлы ысул белән эзләү, алу, тапшыру һәм тарату иреге;

4) гражданнарның шәхси тормыш кагылгысызлыгына, шәхси сергә һәм гаилә серенә, намусны һәм эшлекле репутацияне яклауга хокукын, җирле үзидарә органнары турында мәгълүмат бирелгәндә оешмаларның үз эшлекле репутациясен яклауга хокукын үтәү.

6. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеге күрсәтелгән мәгълүмат Законда билгеләнгән тәртиптә үз эченә дәүләт серен яки закон тарафыннан саклanучы башка серне алган мәгълүмат дип исәпләнгән очракларда чикләнә.

## 2. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүнең ысуллары

1. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеге түбәндәге ысуллар белән тәэмин ителергә мөмкин:

1) ҖҮО ның үз эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында халыкка җиткерүе (бастырып чыгаруы);

2) ҖҮО ның үз эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә урнаштыруы;

3) ҖҮО ның үз эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны күрсәтелгән органнар урнашкан биналарда яки бу максатлар өчен билгеләнгән башка биналарда урнаштыруы;

4) мәгълүматтан файдаланучыларны ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән китапханә һәм архив фондлары аша таныштыру;

5) гражданнарның (физик затларның), шул исәптән оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләренең, коллегиаль ҖҮО утырышларында катнашуы;

6) мәгълүматны мәгълүматтан файдаланучыларның ҖҮО эшчәнлеге хакындагы сораулары буенча бирү;

7) законнарда һәм (яки) башка норматив хокукый актларда, муниципаль норматив хокукый актларда каралган башка ысуллар.

## 3. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген булдыру

1. Мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген булдыру өчен ҖҮО тиешле структур бүлекчәләр яки вәкаләтле вазифаи затлар билгелиләр.

2. Әлеге бүлекчәләр һәм вәкаләтле вазифаи затларның хокуклары һәм бурычлары ҖҮО регламенты, бүлекчәләр турындагы нигезләмәләр һәм (яки) шушы ҖҮО эшчәнлеген җайга салучы башка муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. ҖҮО үз эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны урнаштыру өчен Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтыннан файдаланалар яки мәгълүматтан файдаланучыларга аның аша сорау җибәрергә һәм соралган мәгълүматны алырга мөмкин булган электрон почта адреслары күрсәтелгән үз сайтларын булдыралар.

## 4. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны бирү формалары

1. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат телдән һәм документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә, бирелергә мөмкин.

2. Күрсәтелгән мәгълүмат соралган формада бирелә алмаса, ул ҖҮО карамагында булган формада бирелә.

ҖҮО эшчәнлеге хакындагы телдән мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучыларга кабул итү вакытында бирелә. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук ҖҮО ның белешмәлек хезмәтенең яки мәгълүмат бирергә вәкаләте булган вазифаи затларның телефоннары аша бирелә.

## 5. Мәгълүматтан файдаланучыларның хокуклары

Мәгълүматтан файдаланучы ФЗ № 8-ФЗ Федераль законның 8 матдәсендә каралган хокукларга ия:

1) ҖҮО эшчәнлеге хакында дөрес мәгълүмат алырга;

2) ҖҮО эшчәнлеге хакында мәгълүмат алудан баш тартырга;

3) ҖҮО ның мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеге чикләнмәгән эшчәнлеге хакында соралган мәгълүматның кирәклеген нигезләмәскә;

4) билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар, әлеге органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затлары актларына һәм (яисә) гамәлләренә, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану

хокукын бозучы һәм аны гамәлгә ашыруның билгеләнгән тәртибенә шикаять бирергә;;

5) ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану хокукы бозылу аркасында үзенә китерелгән зыянны каплауны таләп итәргә.

## 6. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны игълан итү (бастырып чыгару)

1. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында игълан итү (бастырып чыгару) “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында” гы 9 февраль 2009 ел № 8-ФЗ Федераль законында каралган очраклардан кала, Россия Федерациясенең массакүләм мәгълүмат чаралары турындагы законнарына туры китереп башкарыла.

Җирле үзидарә органнары карарларын рәсми игълан итү Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставының 67 матдәсенә таянып башкарыла.

2. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматның исемлеге ҖҮО карары белән раслана. Исемлеккә үзгәрешләр кертү аны раслау өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Исемлеккә “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында” гы Федераль законда күздә тотылган мәгълүмат кертелергә тиеш.

Мәгълүматны рәсми сайтта урнаштыруның мәгълүматтан файдаланучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үз вакытында гамәлгә ашыруны һәм яклауны тәэмин итәрдәй вакыт периодлылыгы, мәгълүматны яңартып тору сроклары, күрсәтелгән мәгълүматны урнаштыруга башка төр таләпләр әлеге карар белән билгеләнә.

3. ҖҮО үз эшчәнлеге хакында агымдагы мәгълүмат белән мәгълүматтан файдаланучыларны таныштыру өчен күрсәтелгән органнар урнашкан биналарда яки бу максатлар өчен билгеләнгән башка биналарда мәгълүмат стендлары һәм (яки) шундый ук максатларда билгеләнгән башка техник средстволар урнаштыралар.

Күрсәтелгән мәгълүмат үз эченә алырга тиеш:

1) гражданнарны (физик затларны), шул исәптән оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм ҖИҮ вәкилләрен, кабул итү тәртибен дә кертеп, ҖҮО ның эш тәртибен;

2) ҖҮО дан мәгълүмат алу шартларын һәм тәртибен.

## 7. Коллегиаль ҖҮО утырышларында катнашу

1. Коллегиаль ҖҮО гражданнарга (физик затларга), шул исәптән оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм ҖИҮ вәкилләренә үз утырышларында катнашу мөмкинлеген тәэмин итәләр.

Катнашу ҖҮО регламентларына яки башка муниципаль хокукый актларга туры китереп гамәлгә ашырыла.

2. Теләүчеләрнең катнаша алуын тәэмин итү өчен коллегиаль ҖҮО булачак утырышлар хакында Интернет челтәрендә, мәгълүмат стендларында яки массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырырга тиешләр. Утырыш үткәргәннән соң, җирле үзидарә органы шушы ук чыганакларда утырыш нәтиҗәләре хакында мәгълүмати белдерү урнаштыра.

## 8. ҖҮО һәм аның вазифаи затларының эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны сорап алу

1. Мәгълүматтан файдаланучы сорау белән ҖҮО турыдан-туры яки вәкаләтләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән вәкилләре аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Сорауда аңа җавап җибәрү яки ачыклау өчен почта адресы, телефон һәм (яки) факс номеры, яки электрон почта адресы, шулай ук ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны сораучы гражданның (физик затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме яки оешманың, дәүләт органының исеме күрсәтелә. Аноним сораулар каралмый.

3. Язмача куелган сорауда шулай ук сорау җибәрелүче ҖҮО исеме яки тиешле вазифаи затның фамилиясе, инициаллары яки вазифасының исеме күрсәтелә.

Сорау куелганда Татарстан Республикасы дәүләт телләре файдаланыла.

4. № 8 ФЗ ның 18 матдәсенә туры китереп, язмача куелган сорау, ул ҖҮО килгәннән соң өч көн эчендә, теркәлергә тиеш. Телдән куелган сорау, датаны һәм куелу вакытын күрсәтеп, куелган көндә теркәлә.

5. Россия Федерациясе законнарында башка төрлесе күздә тотылмаган булса, куелган сорау теркәү узганнан соң утыз көнлек срокта каралырга тиеш.

Соралган мәгълүматны күрсәтелгән срокта бирү мөмкин булмаган очракта, сорау теркәлгәннән соң җиде көн эчендә мәгълүматтан файдаланучыга, сәбәбен һәм сораугa җавап бирүнең "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында" гы 9 февраль 2009 ел № 8-ФЗ Федераль законында билгеләнгән срогыннан унбиш көннән артык булмаган мәгълүмат җибәреләчәк срокны күрсәтеп, сорауга җавапның кичектерелүе хакында хәбәр ителә.

6. Әгәр сорау ул җибәрелгән ҖҮО эшчәнлегенә кагылмаса, теркәлгәннән соң җиде көн эчендә сорау соралган мәгълүматны бирергә вәкаләте булган дәүләт органына яки ҖҮО җибәрелә. Шушы ук срокта сорауны куйган мәгълүматтан файдаланучыга сорауның башка адреска җибәрелүе хакында хәбәр ителә. Әгәр ҖҮО башка дәүләт органында, ҖҮО соралган мәгълүматның булу-булмавы хакында хәбәрдар булмаса, сорауны куйган мәгълүматтан файдаланучыга сорау теркәлгәннән соң җиде көн эчендә бу хакта шулай ук хәбәр ителә.

7. Үз эшчәнлеге хакында мәгълүматтан файдаланучыга кирәкле мәгълүматны бирү максатында ҖҮО сорауның эчтәлеген анықларга хокуклы.

## 9. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны сорау буенча бирү тәртибе

1. ҖҮО эшчәнлеге хакында сорау буенча мәгълүмат үз эченә соралган мәгълүматны яки бу мәгълүматны бирүдән мотивацияләнгән баш тартуны керткән яки аңа болар беркетелгән сорауга җавап рәвешендә бирелә. Сорауга җавапта җирле үзидарә органының исеме, почта адресы, җавапны имзалаган затның вазифасы, шулай ук сорауга җавапның реквизитлары (теркәү номеры һәм дата) күрсәтелә.

2. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы сорау массакүләм мәгълүмат чараларында басылган яки рәсми сайтларда урнаштырылган булганда, җирле үзидарә органы үз җавабында массакүләм мәгълүмат чарасының исемен, аның сорау басылган номерын, чыгу вакытын, һәм (яки) сорау урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресын күрсәтү белән чикләнергә мөмкин.

3. Соралган мәгълүмат файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматларга кергән очракта, сорауга җавапта бу мәгълүмат белән файдалануның чикләнгәнлеге хакындагы актның төре, исеме, номеры һәм кабул итү вакыты күрсәтелә. Соралган мәгълүматның бер өлеше файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматларга кергән, калган өлеше белән гомуми файдалану мөмкинлеге булган очракта, җирле үзидарә органы соралган мәгълүматны файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматны төшереп калдырып бирергә бурычлы.

4. Сорауга җавап җирле үзидарә органы тарафыннан мәҗбүри теркәлергә тиеш.

5. Язма сорауга һәм аңа җавапка карата югарыда күрсәтелгән таләпләр җирле үзидарә органына Интернет челтәре аша кергән сорауга һәм аңа җавапка карата да кулланылалар.

## 10.ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны бирү мөмкинлеген төшереп калдыруның нигезләре

1. “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында” гы 9 февраль 2009 ел № 8-ФЗ Федераль законына туры китереп, ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат түбәндәге очракларда бирелми, әгәр:

1) сорауның эчтәлегеннән ҖҮО эшчәнлеге хакында нинди мәгълүмат соралуын аңлау мөмкин булмаса;
2) сорауга җавап җибәрү өчен сорауда почта адресы, электрон почта адресы яки факс номеры яки бу сорауны җибәрүче мәгълүматтан файдаланучының элемтә өчен телефон номеры күрсәтелмәгән булса;
3) соралган мәгълүмат сорау кергән ҖҮО эшчәнлегенә кагылмаса;

4) соралган мәгълүмат файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматларга керсә;
5) соралган мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучыга элек җибәрелгән булса;
6) сорауда ҖҮО кабул иткән актларга хокукый бәя бирү, ҖҮО яки аңа буйсынган оешмалар эшчәнлегенә анализ үткәрү яки башка төр аналитик эш башкару турында сорауны җибәрүче мәгълүматтан файдаланучының хокукларын яклау белән турыдан-туры бәйләнештә булмаган сораулар куелган булса.

2. ҖҮО үз эшчәнлеге хакындагы мәгълүматны, әгәр ул мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында басылган яки Интернет челтәрендә урнаштырылган булса, сорау буенча бирмәскә хокуклы.

3. ҖҮО эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат сорау буенча бирелгән очракта, аның өчен түләү, әгәр соралган һәм алынган мәгълүматның күләме бушлай бирелүче мәгълүматның Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән күләменнән артып китсә, алына. Түләү алу тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

4. Әлеге матдәнең 1 өлешендә күздә тотылган очракта соралган документларның һәм (яки) материалларның күчерелмәләрен эшләүгә киткән, шулай ук аларны почта аша җибәрү белән бәйле чыгымнар мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан түләнә.

## 11. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану тәртибен бозган өчен җаваплылык

1. ҖҮО һәм аларның вазифаи затлары эшчәнлеге хакындагы мәгълүмат белән файдалану хокукын бозуга китергән ҖҮО, аның вазифаи затлары карарлары һәм гамәлләре (бер нәрсә дә эшләмәүләре) хакында югарыдагы органга яки судка шикаять бирелергә мөмкин.